СОВЕТ
СТАРОЧУРИЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д. 52, с. Старое Чурилино,
Арский муниципальный район, 422014

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮРИЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яңа урам, 52 йорт, Иске Чүриле авылы,
Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48,3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail:Shur.Ars@tatar.ru

**Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**«27» декабрь 2021 ел** **№ 37**

**«Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында» Иске Чүриле авыл җирлеге Советының 2019 елның 16 маендагы 76 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**
**(22.09.2020 ел, № 6 үзгәрешләр белән).**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы (25.06.2013 № 50-ТРЗ), «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә торган хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 30 октябрендәге 1029 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайланулы вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы карары,Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Уставы нигезендә Иске Чүриле авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Арча муниципаль районы Иске Чүриле  авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм  аерым хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү күләме һәм шартлары турында» 2019 елның 16 маендагы 76 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Арча муниципаль районы Иске Чүриле  авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәте өчен түләү турындагы нигезләмәнең 34 нче абзацына (2 нче кушымта) түбәндәге абзацлар өстәргә:

«Муниципаль хезмәткәр ул элек биләгән вазыйфалар төркеменә караганда югарырак муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән очракта,  биләгән вазыйфалар төркеме өчен беренче классны чин бирелгәнче, аның биләгән вазыйфасы кергән вазыйфалар төркеме өчен беренче классны чин бирелгәнче классны чин өчен оклад күләме вазыйфаи окладка карата процент ставкасыннан өч процентка тигез итеп исәпләнә.

Муниципаль хезмәткәр элек биләгән вазыйфадан түбәнрәк төркемгә караган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә һәм элек биләгән вазыйфасы буенча аңа классны чин бирелгән очракта, классны чин өчен оклад күләме вазыйфаи окладка карата процент ставкасыннан җиде процентка тигез итеп исәпләнә».

2) «Арча муниципаль районы Иске Чүриле  авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү күләме һәм шартлары турында» 2019 елның 16 маендагы 76 номерлы карарның 3 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

3) «Арча муниципаль районы Иске Чүриле  авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү күләме һәм шартлары турында» 2019 елның 16 маендагы 76 номерлы карарының 6 нчы кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. «Арча муниципаль районы Иске Чүриле  авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү күләме һәм шартлары турында» 2019 елның 16 маендагы 76 номерлы карарының 7 нче кушымтасын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегенә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Чүриле  авыл җирлеге башлыгы  Р.Т.Һидиятуллин

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «СТАРОЧУРИЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012646

Иске Чүриле авыл җирлеге Советының
27.12.2021 ел, №37 карарына
3 нче кушымта

**Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү күләме һәм шартлары турында нигезләмә**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге хезмәткәрләренең хезмәт хакы айлык тариф ставкасыннан, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, еллык түләүле отпуск, матди ярдәм күрсәткәндә матди ярдәмнән, шулай ук законнар нигезендә башка түләүләрдән тора;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге эшчәнлегенә хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү разрядлары диапазоны 5 нче кушымта нигезендә билгеләнә;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге хезмәткәрләренең айлык тариф ставкалары күләмнәре 6 нчы кушымта нигезендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге хезмәткәрләренә түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

2) еллык түләүле отпуск биргәндә, айлык тариф ставкасының (окладның) 50 % күләмендә матди ярдәм.

Әгәр хезмәткәргә календарь ел дәвамында еллык түләүле отпуск бирелмәгән булса, еллык түләүле отпуск биргәндә матди ярдәм аңа эшләнгән эшләргә пропорциональ рәвештә исәпләп чыгарыла һәм декабрьдә түләнә, эштән киткән очракта - соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча түләнә.

Еллык түләүле отпуск биргәндә, хезмәткәргә эшенең беренче елында матди ярдәм түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы елның 31 декабренә кадәр исәпләнә;

3) хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә матди ярдәм;

Хезмәткәрләргә тиешле федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда каралган башка түләүләр башкарырга.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге хезмәткәрләренә айлык һәм башка түләүләрнең күләмнәре арту ягына бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш дип билгеләргә.

Иске Чүриле авыл җирлеге
Советының
27.12.2021 ел, №37 карарына
6 нчы кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (окладлары)**

| Бердәм тариф челтәренә түләү разряды | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкасы (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0000 | 13 617,0 |
| 2 | 1,0178 | 13 860,0 |
| 3 | 1,0362 | 14 110,0 |
| 4 | 1,0538 | 14 350,0 |
| 5 | 1,0736 | 14 620,0 |
| 6 | 1,0927 | 14 880,0 |
| 7 | 1,1133 | 15 160,0 |
| 8 | 1,1331 | 15 430,0 |
| 9 | 1,1530 | 15 700,0 |
| 10 | 1,1743 | 15 990,0 |
| 11 | 1,1948 | 16 270,0 |
| 12 | 1,2168 | 16 570,0 |
| 13 | 1,2389 | 16 870,0 |
| 14 | 1,2609 | 17 170,0 |
| 15 | 1,2837 | 17 480,0 |
| 16 | 1,3072 | 17 800,0 |
| 17 | 1,3307 | 18 120,0 |
| 18 | 1,3549 | 18 450,0 |